# Казан – Татарстанның башкаласы



Казан – борынгы шәһәр. Ул Иделнең сул ярында урнашкан. Казанның мәйданы – 288 кв.км. Анда 1 миллионнан артык кеше яши. Шәһәр 7 районга бүленгәп: Вахитов, Совет, Киров, Мәскәү, Идел буе, Яңа Савин һәм Авиатөзелеш районнары.



Казанның үзәгендә тарихи һәйкәл – Кремль Биредә, Президент Сарае, Сөембикә Манарасы, Благовещение соборы урнашкан.





Казан – эре промышленность үзәге. Биредә самолётлар, медицина җиһазлары, магнитлы тасмалар, мех һәм тегү әйберләре, дарулар җитештерелә.





Казанда югары уку йортлары күп. Шулай ул Казан шәһәрендә 6 театр эшли: М.Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театры,



Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры,





В.Качалов исемендәге Зур рус драма академия театры,



К.Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театры,



Яшь тамашачы театры,



Курчак театры.



Бүгенге Казан зур, матур, мәһабәт. 2005 нче елда Казан үзенең меңьеллыгын бәйрәм итте.

